**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“28” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Яңа Шашы авылы территориясендә куаклар, агачлар кисү һәм чистарту;
- Яңа Шашы авылында су башнясын койма белән әйләндереп алу өчен төзү материаллары алу һәм эш өчен түләү;

2) Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Яңа Шашы авылында юлларны төзекләндерүгә вак таш алу һәм транспорт хезмәте өчен түләү.

.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.